# Мусина Руфия Кирам кызы



Мусина Руфия Кирам кызы 1950 нче елның 12 октябрендә Сарман районы Теләнче Тамак авылында туган. 1967 нче елда Мөслим урта мәктәбен тәмамлый. 1968 нче елда Алабуга дәүләт педагогия институтының филология факультетына укырга керә. Институтны тәмамлагач, Мөслим районы Шуганка, Мәллә Тамак авылларында укыта. 1974 нче елда Мөслим районының Бөтенсоюз Ленин Коммунистик яшьләр берлегенә (РК ВЛКСМ) сәркатип итеп билгеләнә. 1976 нче елдан Мөслим урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли башлый. Хезмәтенең унсигез елдан артыгын җитәкче постларда: уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары, 1987 нче елда Мөслим башлангыч мәктәбе директоры, 1995 нче елда Мөслим урта мәктәбе директоры вазыйфаларын башкара. Шунысы игътибарга лаек: Мөслим урта мәктәбе тарихында Руфия Кирам кызы – беренче хатын-кыз директор. Тирән белемле, туры сүзле, сабыр, акыллы, ир-ат характерлы, сәләтле җитәкче була ул. Күп еллык фидакарь хезмәте өчен 1987 нче елда “Халык мәгарифе отличнигы” дигән мәртәбәле исемгә лаек була. 1992 нче елда “Методист –укытучы” категориясе бирелә. 1998 нче елда “Әйдәп баручы директор” дигән квалифакацион категориягә лаек була. Эшләү дәверендә Татарстан Республикасының Мәгариф министрлыгының Мактау грамоталары белән бүләкләнә. 2000 нче елда Мәскәүдә Россия укытучыларының тантаналы җыелышында катнашу бәхетенә дә ирешә. Утыз тугыз елдан артык гомерен балалар укытуга багышлаган Руфия Кирам кызының үткән тормыш һәм хезмәт юлында башкалар сокланырлык, үрнәк алырлык яклар гаять күп.